КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июль г.Казань № 563

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итү турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү аркасында гражданнарның һәм юридик затларның күргән зыяннарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә Африка дуңгыз чумасы чыгу урыннары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территориясендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 5 июлендәге ПУ-550 номерлы Указының 2 пунктындагы «б» пунктчасында билгеләнгән территориядә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне гамәлгә ашырырга.

2. Бу карарга теркәлгән Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне башкару буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 пункты белән күздә тотылган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 9 июль, 563 нче
карары белән расланды

Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын
алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Галимуллин Айрат Наил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Түбән Кама территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Гатин Идрис Мөдәррис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Камалов Ильяс Локман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Алексеевск территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Латыйпов Солтан Сәлим улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| Мөхәммәтҗанов Реваль Рөстәм улы | «Әлмәт район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Никитин Андрей Михайлович | «Яңа Чишмә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Фәсахов Ринат Рифгать улы | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәрәпов Ранил Ринат улы | «Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы. |